итү һәм эш йөртү вәкаләтләрен Татарстан Республикасы гамәлгә ашыра торган башка муниципаль берәмлекләр территориясендә урнашкан җир кишәрлекләреннән бирелә.»;

б) 8 пунктның беренче абзацында «муниципаль милектәге җир кишәрлекләре, шулай ук үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 14[1] пункт өстәргә:

«14[1]. Идарә итү һәм эш йөртү вәкаләтләрен Татарстан Республикасы гамәлгә ашыра торган җир кишәрлекләрен бирү турында карар әлеге статьяның 13 пунктында күрсәтелгән акт нигезендә имза салынганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан кабул ителә.»;

г) түбәндәге эчтәлекле 19[1] пункт өстәргә:

«19[1]. Әлеге статьяның 5 пункты нигезендә җир кишәрлекләре бирелгәндә башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасындагы хезмәттәшлек тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

16) 33[1] статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

17) 34 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34 статья. **Җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм максималь) күләмнәре**»;

б) 1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы милкендәге» сүзләрен «Дәүләт милкендәге» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы милкендәге» сүзләрен «Дәүләт милкендәге» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 4 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

е) 5 һәм 6 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

18) 36 статьяда:

а) 1 пунктта «милекчедән аның җир кишәрлеген мәҗбүри рәвештә тартып алу нәтиҗәсендә милекче граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «милекче граждан һәм җир законнарында каралган башка нигезләрдә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта:



беренче абзацта «Россия Федерациясе Җир кодексында билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә» сүзләрен «Россия Федерациясе Җир кодексында каралган шартларда һәм тәртиптә, граждан һәм җир законнарында билгеләнгән башка нигезләрдә» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукы, җир кишәрлеген мирас итеп калдырырлык гомерлек биләү хокукы Россия Федерациясе Җир кодексында билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә мәҗбүри туктатыла.»;

19) 37 статьяда:

а) исемендә «, шул исәптән сатып алу» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен аерып алу Россия Федерациясе Җир кодексында һәм федераль законнарда билгеләнгән аерым очракларда гына гамәлгә ашырыла.»;

в) 2 пунктта «һәм муниципаль» сүзләрен «яисә муниципаль» сүзләренә алмаштырырга»;

г) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

20) 37[1] статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

21) 38 статьяда:

а) исемендә «Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен аерып алганда,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) текстта «Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен аерып алганда,» сүзләрен төшереп калдырырга;

22) 43 статьяда:

а) 1 пунктта «сату очракларыннан» сүзләреннән соң «һәм җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен аерып алу очракларыннан» сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктның беренче абзацында «туксан» сүзен «90» саннарына алмаштырырга;

в) 3 пунктның дүртенче абзацында «утыз» сүзен «30» саннарына алмаштырырга;

23) 44 статьяда:

а) исемендә «Татарстан Республикасы» сүзләрен «Дәүләт» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «Татарстан Республикасы» сүзләрен «Дәүләт» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен билгеләнгән һәм гражданга яисә юридик затка арендага бирелгән җир кишәрлеге, әлеге граждан яисә әлеге юридик зат мондый җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә сату-алу шартнамәсен төзү турындагы гаризаны җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсенең срогы тәмамланачак көнгә кадәр биргән очракта, әлеге граждан яисә әлеге юридик зат белән аренда килешүе төзелгән йә җир кишәрлеген арендалауның күрсәтелгән шартнамәсе буенча хокуклар һәм йөкләмәләр әлеге гражданга яисә әлеге юридик затка тапшырылган вакыттан соң өч ел үткәч, мондый җир кишәрлегеннән тиешенчә файдалану шарты белән, әлеге граждан яисә әлеге юридик зат тарафыннан милеккә сатып алынырга мөмкин.»;

г) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

24) 45 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«45 статья. **Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләре әйләнешенә, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләренә гомуми милек хокукындагы өлешләр әйләнешенә бәйле хәбәрләрне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару»;**

б) 45 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган массакүләм мәгълүмат чараларында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләре әйләнешенә, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләренә гомуми милек хокукындагы өлешләр әйләнешенә бәйле түбәндәге хәбәрләр бастырып чыгарыла:

1) муниципаль милектәге җир өлешләре исәбеннән бүлеп бирелгән җир кишәрлеге сатып алу мөмкинлеге турында мәгълүмат;

2) муниципаль милектәге җир өлеше сатып алу мөмкинлеге турында мәгълүмат;

3) файдаланылмый торган җир өлешләре исемлеге;

4) җир кишәрлекләрен ызанлау проекты белән танышу урыны һәм тәртибе турында хәбәр;

5) җир кишәрлекләрен ызанлау проектын килештерү зарурлыгы турында хәбәр;



6) өлешле милектә катнашучыларның гомуми җыелышы булачагы турында өлешле милектә катнашучыларга хәбәр итү.»;

25) 46 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 31 июлендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 4 пунктының «а» һәм «б» пунктчалары, 12 пункты (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2014, № 5);

2) «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 17 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 5 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2014 елның 14 маендагы 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 6 пункты (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 5);

4) «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында» 2014 елның 23 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 7);

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 07 мае
№ 32-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 413. Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4, № 6 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2 статья. **Гаилә законнары белән җайга салына торган мөнәсәбәтләр**

Гаилә законнары гаилә хокукларын гамәлгә ашыру һәм яклау тәртибен, никахлашуның, аны туктатуның һәм дөрес түгел дип тануның шартларын һәм тәртибен билгели, гаилә әгъзалары: ир белән хатын, ата-ана һәм балалар (уллыкка алучылар һәм уллыкка алынучылар) арасында, ә гаилә законнарында каралган очракларда һәм чикләрдә башка туганнар һәм бүтән затлар арасында мөлкәти булмаган һәм мөлкәти булган шәхси мөнәсәбәтләрне җайга сала, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны ачыклау тәртибен, аларны гаиләгә урнаштыру, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларга вакытлыча урнаштыру рәвешләрен һәм тәртибен билгели.»;

2) 6 статьяның 2 өлешендә «ысуллар» сүзеннән соң «, шулай ук законда каралган башка ысуллар» сүзләрен өстәргә;

3) 27 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. Ир белән хатынның берсе хокуклары дәүләт теркәвенә алынырга тиешле мөлкәт белән эш йөртү буенча алыш-бирешне, закон белән мәҗбүри нотариаль рәвеше билгеләнгән алыш-бирешне яисә мәҗбүри дәүләт теркәвенә алынырга тиешле алыш-



бирешне башкару өчен каршы якның нотариаль расланган ризалыгын алырга тиеш.»;

4) 29 статьяда «ачыкланса,» сүзеннән соң «суд тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

5) 42 статьяның 2 өлешендә «баланың атасы гаризасы буенча» сүзләреннән соң «(әлеге Кодексның 39 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләре)» сүзләрен өстәргә;

6) 53 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Никахлашмаган балигъ булмаган ата-ананың баласы туган очракта һәм аларның ана һәм (яисә) ата булулары билгеләнгәндә, алар, уналты яшькә җиткәч, ата-ана хокукларын мөстәкыйль гамәлгә ашырырга хокуклы. Балигъ булмаган ата-ана уналты яшькә җиткәнче, аларның баласына опекун билгеләнә, опекун баланың балигъ булмаган ата-анасы белән бергә аны тәрбияли. Баланың опекуны белән балигъ булмаган ата-ана арасында килеп чыга торган каршылыклар опека һәм попечительлек органы тарафыннан хәл ителә.»;

7) 57 статьяда:
а) 5 өлештә «граждан-процессуаль законнарында» сүзләрен «административ хокук бозулар турындагы законнарда һәм башкару эшчәнлеге хакындагы законнарда» сүзләренә алмаштырырга;
б) 6 өлештә «халыкны социаль яклау учреждениеләреннән» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларыннан» сүзләренә алмаштырырга;

8) 58 статьяның 4 өлешендә «граждан-процессуаль законнарында» сүзләрен «административ хокук бозулар турындагы законнарда һәм башкару эшчәнлеге хакындагы законнарда» сүзләренә алмаштырырга;

9) 60 статьяда:
а) 1 өлешнең 2 пунктында «халыкны социаль яклау учреждениесеннән» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмасыннан» сүзләренә алмаштырырга;
б) 1 өлешнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) үз балаларының, балаларның атасының йә анасының, иренең йә хатынының, шул исәптән балаларның атасы йә анасы булмаган иренең йә хатынының гомеренә яисә сәламәтлегенә кар-

шы йә гаиләнең башка әгъзасының гомеренә яисә сәламәтлегенә каршы белә торып җинаять кылсалар.»;

10) 65 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«65 статья. **Атасының йә анасының ата-ана хокуклары суд тарафыннан чикләнгән баланың атасы йә анасы белән аралашуы**

Ата-ана хокуклары суд тарафыннан чикләнгән атасына йә анасына бала белән аралашу, әгәр балага зарарлы йогынты ясалмаса, рөхсәтителергә мөмкин. Атасының йә анасының бала белән аралашуы опека һәм попечительлек органы ризалыгы белән йә ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителмәгән яисә ата-ана хокуклары чикләнмәгән атасы йә анасы, опекун (попечитель), баланы тәрбиягә алган ата-ана яисә бала тора торган оешма администрациясе ризалыгы белән рөхсәт ителә.»;

11) 69 статьяда «граждан-процессуаль законнарында» сүзләрен «башкару эшчәнлеге турындагы законнарда» сүзләренә алмаштырырга;

12) 74 статьяның 2 өлешендә «халыкны социаль яклау учреждениеләрендәге» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларындагы» сүзләренә алмаштырырга;

13) 80 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында «ярдәмгә мохтаҗ» сүзләреннән соң «элеккеге» сүзен өстәргә;

14) 100 статьяның 2 өлешендә «граждан-процессуаль законнарында» сүзләрен «башкару эшчәнлеге турындагы законнарда» сүзләренә алмаштырырга;

15) 116 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктында «уллыкка алуны билгеләү» сүзләрен «уллыкка алу» сүзләренә алмаштырырга;

16) 120 статьяның 3 өлешендә «халыкны социаль яклау учреждениеләрендә» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан



Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 9 – 10; 2010, № 11; 2014, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә «учреждениеләренең» сүзен «оешмаларының» сүзенә алмаштырырга;

2) 2 өлешнең беренче абзацында «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 өлешенең 5 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) стационар рәвештә социаль хезмәт күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында яшәүче олы яшьтәге гражданнар һәм инвалидлар;».

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 07 мае
№ 33-ТРЗ

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 414. 2015 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 31маенда
кабул ителде

### 1 статья

2015 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 203 921 818,4 мең сум һәм чыгымнар буенча 211 021 816,3 мең сум күләмендә, чыгымнарның керемнәрдән артуын 7 099 997,9 мең сум күләмендә һәм түбәндәге күрсәткечләре белән расларга:

1) әлеге Законның 1 нче кушымтасы нигезендә бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;

2) әлеге Законның 2 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары;

3) әлеге Законның 3 нче кушымтасы нигезендә бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары;

4) әлеге Законның 4 нче кушымтасы нигезендә бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары.

### 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2016 елның 31 мае
№ 34-ТРЗ



«2015 елгы
Татарстан Республикасы
бюджеты үтәлеше турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

Бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча
2015 елгы Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Табигатьтән файдалану өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең (Росприроднадзор) Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 048 | | 348 180,9 |
| Атмосфера һавасына стационар объектлардан пычраткыч матдәләр чыгарган өчен түләү | 048 | 1 12 01010 01 0000 120 | 17 350,8 |
| Атмосфера һавасына күчмә объектлардан пычраткыч матдәләр чыгарган өчен түләү | 048 | 1 12 01020 01 0000 120 | 3 283,0 |
| Су объектларына пычраткыч матдәләр чыгарган өчен түләү | 048 | 1 12 01030 01 0000 120 | 143 959,8 |
| Җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләү | 048 | 1 12 01040 01 0000 120 | 143 696,9 |
| Нефтькә ияреп чыккан газны факел җайланмаларында яндырганда һәм (яисә) таратканда барлыкка килә торган пычраткыч матдәләр чыгарган өчен түләү | 048 | 1 12 01070 01 0000 120 | 39 890,4 |
| Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы | 053 | | 123,9 |
| Янгын куркынычсызлыгы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 053 | 1 16 27000 01 0000 140 | 123,9 |
| Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә федераль күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 096 | | 883,0 |
| Продукциясе нигездә Россия Федерациясе субъекты территориясендә тарату өчен билгеләнгән массакүләм мәгълүмат чараларын дәүләт теркәвенә алган өчен, шулай ук мондый теркәү турындагы таныклыкның дубликатын биргән өчен дәүләт пошлинасы | 096 | 1 08 07130 01 0000 110 | 883,0 |

| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Федераль казначылыкның вәкаләтле органы | 100 | | 6 861 050,1 |
| Дизель ягулыгына акцизлар түләүдән Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм җирле бюджетлар арасында, җирле бюджетларга билгеләнгән дифференциацияләнгән түләүләр нормативларын исәпкә алып, бүленергә тиешле керемнәр | 100 | 1 03 02230 01 0000 110 | 2 393 732,2 |
| Дизель һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлар түләүдән Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм җирле бюджетлар арасында, җирле бюджетларга билгеләнгән дифференциацияләнгән түләүләр нормативларын исәпкә алып, бүленергә тиешле керемнәр | 100 | 1 03 02240 01 0000 110 | 64 847,9 |
| Автомобиль бензинына акцизлар түләүдән Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм җирле бюджетлар арасында, җирле бюджетларга билгеләнгән дифференциацияләнгән түләүләр нормативларын исәпкә алып, бүленергә тиешле керемнәр | 100 | 1 03 02250 01 0000 110 | 4 715 940,8 |
| Турыдан-туры куыла торган бензинга акцизлар түләүдән Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары һәм җирле бюджетлар арасында, җирле бюджетларга билгеләнгән дифференциацияләнгән түләүләр нормативларын исәпкә алып, бүленергә тиешле керемнәр | 100 | 1 03 02260 01 0000 110 | -307 874,7 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган 280нән 360 Цельсий градусына кадәр температура интервалында кайнаучы турыдан-туры куыла торган һәм (яисә) икенчел барлыкка килгән дизель фракцияләреннән чыгарыла торган көнкүреш мич ягулыгына акцизлар түләүдән керемнәр суммаларын Россия Федерациясе субъектларының бюджетлары керемнәре исәбеннән кайтару | 100 | 1 03 02290 01 0000 110 | -5 596,1 |
| Транспорт өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча дәүләт автомобиль юлы күзәтчелеге идарәсе | 106 | | 367,40 |



| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Юл хәрәкәте иминлеге турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 106 | 1 16 30020 01 0000 140 | 229,9 |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган бүтән кертемнәр | 106 | 1 16 90020 02 0000 140 | 137,5 |
| Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 161 | | 2 238,2 |
| Реклама турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 161 | 1 16 26000 01 0000 140 | 628,0 |
| Россия Федерациясе субъектлары ихтыяҗлары өчен, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 161 | 1 16 33020 02 0000 140 | 1 610,2 |
| Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар зыяннарын бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе | 177 | | 18 992,2 |
| Янгын куркынычсызлыгы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 177 | 1 16 27000 01 0000 140 | 18 992,2 |
| Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 182 | | 154 902 992,2 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган оешмалар (салым түләүчеләрнең берләштерелгән төркемнәреннән тыш) табышына салым | 182 | 1 01 01012 02 0000 110 | 46 682 054,8 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган салым түләүчеләрнең берләштерелгән төркемнәреннән оешмалар табышына салым | 182 | 1 01 01014 02 0000 110 | 25 608 817,6 |

| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| «Продукция бүлешү турындагы килешүләр хакында» 1995 елның 30 декабрендәге 225-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергәнче төзелгән һәм әлеге салымны федераль бюджетка һәм Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерү өчен махсус салым ставкаларын күз алдында тотмый торган продукция бүлешү турындагы килешүләрне үтәгәндә оешмалар табышына салым | 182 | 1 01 01020 01 0000 110 | -13,5 |
| Салым исәпләү һәм түләү Россия Федерациясе Салым кодексының 227, $227^{1}$ һәм 228 статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла торган керемнәрдән тыш, чыганагы салым агенты булган керемнәрдән физик затлар керемнәренә салым | 182 | 1 01 02010 01 0000 110 | 38 859 224,3 |
| Россия Федерациясе Салым кодексының 227 статьясы нигезендә индивидуаль эшкуарлар, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариуслар, адвокат кабинетларын гамәлгә куйган адвокатлар һәм хосусый практика белән шөгыльләнүче башка затлар буларак теркәлгән физик затларның үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашырудан алынган керемнәрдән физик затлар керемнәренә салым | 182 | 1 01 02020 01 0000 110 | 153 906,4 |
| Россия Федерациясе Салым кодексының 228 статьясы нигезендә физик затларның алынган керемнәреннән физик затлар керемнәренә салым | 182 | 1 01 02030 01 0000 110 | 630 487,2 |
| Россия Федерациясе Салым кодексының $227^{1}$ статьясына таянып, патент нигезендә наем буенча хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы чит ил гражданнары булып торучы физик затлар тарафыннан алынган керемнәрдән расланган аванс түләүләре рәвешендә физик затлар керемнәренә салым | 182 | 1 01 02040 01 0000 110 | 446 404,9 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган азык-төлек чималыннан этил спиртына (шәраб, виноград, җиләк-җимеш, коньяк, кальвадос, виски дистиллятларыннан тыш) акцизлар | 182 | 1 03 02011 01 0000 110 | -869,2 |



| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган шәрабларга, җиләк-җимеш шәрабларына, күбекле шәрабларга (шампан шәрабына), азык-төлек чималыннан ясалган ректификацияле этил спиртын һәм (яисә) спиртланган виноград яисә башка җиләк-җимеш сосласын, һәм (яисә) шәраб дистиллятын, һәм (яисә) җиләк-җимеш дистиллятын кушмыйча әзерләнгән шәраблы эчемлекләргә акцизлар | 182 | 1 03 02090 01 0000 110 | 10 288,8 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган сырага акцизлар | 182 | 1 03 02100 01 0000 110 | 5 655 572,7 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган, күләм өлешендә этил спирты 9 проценттан артык булган алкогольле продукциягә (сырадан, шәраблардан, җиләк-җимеш шәрабларыннан, күбекле шәраблардан (шампан шәрабыннан), азык-төлек чималыннан ясалган ректификацияле этил спиртын, һәм (яисә) спиртланган виноград яисә башка җиләк-җимеш сосласын, һәм (яисә) шәраб дистиллятын, һәм (яисә) җиләк-җимеш дистиллятын кушмыйча әзерләнгән шәраблы эчемлекләрдән тыш) акцизлар | 182 | 1 03 02110 01 0000 110 | 7 176 464,6 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган сидр, пуаре, әче балга акцизлар | 182 | 1 03 02120 01 0000 110 | 0,2 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган 280нән 360 Цельсий градусына кадәр температура интервалында кайнаучы турыдан-туры куыла торган һәм (яисә) икенчел барлыкка килгән дизель фракцияләреннән чыгарыла торган көнкүреш мич ягулыгына акцизлар | 182 | 1 03 02210 01 0000 110 | 288 825,6 |
| Салым салу объекты буларак керемнәрне сайлаган салым түләүчеләрдән алына торган салым | 182 | 1 05 01011 01 0000 110 | 2 484 038,7 |
| Салым салу объекты буларак керемнәрне сайлаган салым түләүчеләрдән алына торган салым (2011 елның 1 гыйнварына кадәр узган салым чорлары өчен) | 182 | 1 05 01012 01 0000 110 | -173,6 |

| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Салым салу объекты буларак чыгымнар күләменә киметелгән керемнәрне сайлаган салым түләүчеләрдән алына торган салым | 182 | 1 05 01021 01 0000 110 | 952 631,8 |
| Салым салу объекты буларак чыгымнар күләменә киметелгән керемнәрне сайлаган салым түләүчеләрдән алына торган салым (2011 елның 1 гыйнварына кадәр узган салым чорлары өчен) | 182 | 1 05 01022 01 0000 110 | -1 601,4 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган минималь салым | 182 | 1 05 01050 01 0000 110 | 387 868,0 |
| Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасына керми торган мөлкәт буенча оешмалар мөлкәтенә салым | 182 | 1 06 02010 02 0000 110 | 20 750 302,3 |
| Газ белән тәэмин итүнең бердәм системасына керә торган мөлкәт буенча оешмалар мөлкәтенә салым | 182 | 1 06 02020 02 0000 110 | 203 380,6 |
| Оешмалардан транспорт салымы | 182 | 1 06 04011 02 0000 110 | 1 242 886,3 |
| Физик затлардан транспорт салымы | 182 | 1 06 04012 02 0000 110 | 3 260 267,2 |
| Уен бизнесына салым | 182 | 1 06 05000 02 0000 110 | 6 188,9 |
| Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгаруга салым | 182 | 1 07 01020 01 0000 110 | 71 112,9 |
| Башка файдалы казылмалар чыгаруга салым (табигый алмазлар рәвешендәге файдалы казылмалардан тыш) | 182 | 1 07 01030 01 0000 110 | 6 700,8 |
| Хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган өчен җыем | 182 | 1 07 04010 01 0000 110 | 1 035,7 |
| Су биологик ресурслары объектларыннан (эчке су объектларын кертмичә) файдаланган өчен җыем | 182 | 1 07 04020 01 0000 110 | 11,9 |
| Су биологик ресурслары объектларыннан (эчке су объектлары буенча) файдаланган өчен җыем | 182 | 1 07 04030 01 0000 110 | 212,4 |
| Россия Федерациясе субъектлары конституция (устав) судлары карый торган эшләр буенча дәүләт пошлинасы | 182 | 1 08 02020 01 0000 110 | 74,3 |
| Юридик затны, физик затларны индивидуаль эшкуарлар буларак, юридик затның гамәлгә кую документларына кертелә торган үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган өчен, юридик затның бетерелүен дәүләт теркәвенә алган һәм юридик әһәмиятле башка гамәлләр өчен дәүләт пошлинасы | 182 | 1 08 07010 01 0000 110 | 149,9 |



| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Шәһәр округлары территорияләрендә туплана торган һәм җирле бюджетларга 2005 елның 1 гыйнварына кадәр күчерелгән оешмалар табышына салым | 182 | 1 09 01020 04 0000 110 | 847,6 |
| Муниципаль районнар территорияләрендә туплана торган һәм җирле бюджетларга 2005 елның 1 гыйнварына кадәр күчерелгән оешмалар табышына салым | 182 | 1 09 01030 05 0000 110 | 43,2 |
| Гомумтаралган файдалы казылмалар чыгарган өчен муниципаль районнар территорияләрендә туплана торган түләүләр | 182 | 1 09 03021 05 0000 110 | 115,3 |
| Җир асты суларын чыгарган өчен түләүләр | 182 | 1 09 03023 01 0000 110 | 0,1 |
| Минераль-чимал базасын торгызуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган акчалар, моңа җирле ихтыяҗлар өчен файдаланыла торган гомумтаралган файдалы казылмалар һәм җир асты суларын чыгарганда түләнә торган акчалар керми | 182 | 1 09 03082 02 0000 110 | 6,7 |
| Предприятиеләр мөлкәтенә салым | 182 | 1 09 04010 02 0000 110 | 13 854,2 |
| Транспорт чаралары хуҗаларыннан салым һәм автотранспорт чараларын сатып алуга салым | 182 | 1 09 04020 02 0000 110 | 77,1 |
| Автомобиль юлларыннан файдаланучыларга салым | 182 | 1 09 04030 01 0000 110 | 329,3 |
| Мирас яисә бүләк итү рәвешендә күчә торган мөлкәттән салым | 182 | 1 09 04040 01 0000 110 | 2,7 |
| Сатулардан салым | 182 | 1 09 06010 02 0000 110 | 227,0 |
| Мәгариф учреждениеләре ихтыяҗларына юридик затлардан алына торган җыем | 182 | 1 09 06020 02 0000 110 | 0,1 |
| Башка салымнар һәм җыемнар | 182 | 1 09 06030 02 0000 110 | 0,1 |
| Россия Федерациясе территориясендә җир асты байлыкларыннан файдаланганда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләүләр | 182 | 1 12 02030 01 0000 120 | 11 205,4 |
| Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарны бозган өчен Россия Федерациясе Салым кодексының 129² статьясында каралган акчалата түләтүләр (штрафлар) | 182 | 1 16 03020 02 0000 140 | 32,3 |
| Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты | 187 | | 21,8 |

| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Юл хәрәкәте иминлеге турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 187 | 1 16 30020 01 0000 140 | 21,8 |
| Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы | 188 | | 3 666 839,5 |
| Реклама турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 188 | 1 16 26000 01 0000 140 | 6,8 |
| Региональ һәм муниципальара әһәмиятле гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буенча эре габаритлы һәм авыр йөкләр ташу кагыйдәләрен бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 188 | 1 16 30012 01 0000 140 | 3 440,5 |
| Юл хәрәкәте иминлеге турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 188 | 1 16 30020 01 0000 140 | 3 663 392,2 |
| Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 192 | | 1 842,9 |
| Россия Федерациясе гражданлыгы алуга яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгуга, шулай ук Россия Федерациясенә керүгә яисә Россия Федерациясеннән чыгуга бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы (Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданы шәхесен таныклый торган паспорт биргән өчен дәүләт пошлинасы (күпфункцияле үзәкләр аша мөрәҗәгать иткәндә) | 192 | 1 08 06000 01 8003 110 | 1 041,8 |
| Россия Федерациясе гражданлыгы алуга яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгуга, шулай ук Россия Федерациясенә керүгә яисә Россия Федерациясеннән чыгуга бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы (Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданы шәхесен таныклый торган электрон мәгълүмат чыганагы булган паспорт (яңа төр паспорт) биргән өчен дәүләт пошлинасы (күпфункцияле үзәкләр аша мөрәҗәгать иткәндә) | 192 | 1 08 06000 01 8004 110 | 3,5 |



| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Россия Федерациясе гражданлыгы алуга яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгуга, шулай ук Россия Федерациясенә керүгә яисә Россия Федерациясеннән чыгуга бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы (14 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданына Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданы шәхесен таныклый торган паспорт биргән өчен дәүләт пошлинасы (күпфункцияле үзәкләр аша мөрәҗәгать иткәндә) | 192 | 1 08 06000 01 8005 110 | 114,8 |
| Россия Федерациясе гражданлыгы алуга яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгуга, шулай ук Россия Федерациясенә керүгә яисә Россия Федерациясеннән чыгуга бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы (14 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданына Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданы шәхесен таныклый торган электрон мәгълүмат чыганагы булган паспорт (яңа буын паспорт) биргән өчен дәүләт пошлинасы (күпфункцияле үзәкләр аша мөрәҗәгать иткәндә) | 192 | 1 08 06000 01 8006 110 | 0,7 |
| Россия Федерациясе гражданлыгы алуга яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгуга, шулай ук Россия Федерациясенә керүгә яисә Россия Федерациясеннән чыгуга бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы (Россия Федерациясе территориясеннән читтә Россия Федерациясе гражданы шәхесен таныклый торган паспортка үзгәрешләр керткән өчен дәүләт пошлинасы (күпфункцияле үзәкләр аша мөрәҗәгать иткәндә) | 192 | 1 08 06000 01 8007 110 | 8,2 |
| Россия Федерациясе гражданы паспортын биргән яисә алыштырган өчен дәүләт пошлинасы (Россия Федерациясе гражданы паспортын биргән өчен дәүләт пошлинасы (күпфункцияле үзәкләр аша мөрәҗәгать иткәндә) | 192 | 1 08 07100 01 8034 110 | 553,5 |

| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Россия Федерациясе гражданы паспортын биргән яисә алыштырган өчен дәүләт пошлинасы (Россия Федерациясе гражданының югалган яисә яраксыз хәлгә килгән паспорты урынына Россия Федерациясе гражданы паспортын биргән өчен дәүләт пошлинасы (күпфункцияле үзәкләр аша мөрәҗәгать иткәндә) | 192 | 1 08 07100 01 8035 110 | 120,4 |
| Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 318 | | 70,2 |
| Төбәкара, төбәк һәм җирле иҗтимагый берләшмәләрне, иҗтимагый берләшмәләр бүлекчәләрен дәүләт теркәвенә алган өчен, шулай ук аларның гамәлгә кую документларына үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алган өчен дәүләт пошлинасы (башка иҗтимагый берләшмәләрне, иҗтимагый берләшмәләр бүлекчәләрен дәүләт теркәвенә алган өчен дәүләт пошлинасы) | 318 | 1 08 07110 01 0103 110 | 63,2 |
| Сәяси партияләрне һәм сәяси партияләрнең региональ бүлекчәләрен дәүләт теркәвенә алган өчен дәүләт пошлинасы | 318 | 1 08 07120 01 0000 110 | 7,0 |
| Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 321 | | 311 397,2 |
| Күчемсез мөлкәткә хокукларны, хокукларны чикләүләрне (чикләп торуларны) һәм алар белән алыш-биреш итүләрне дәүләт теркәвенә алган өчен дәүләт пошлинасы (күпфункцияле үзәкләр аша мөрәҗәгать иткәндә) | 321 | 1 08 07020 01 8000 110 | 311 397,2 |
| Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 322 | | -5,0 |
| Җинаятьләр кылуда гаепле затлардан һәм мөлкәткә зыянны каплау өчен алына һәм Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган акчалата түләтүләр (штрафлар) һәм бүтән суммалар | 322 | 1 16 21020 02 0000 140 | -5,0 |
| Татарстан Республикасы прокуратурасы | 415 | | 2 186,9 |



| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Реклама турында законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 415 | 1 16 26000 01 0000 140 | 882,7 |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган бүтән кертемнәр | 415 | 1 16 90020 02 0000 140 | 1 304,2 |
| Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | 701 | | 158 796,2 |
| Лицензияләүгә, аттестация уздыруга бәйле, әгәр мондый аттестация Россия Федерациясе законнарында каралган булса, гамәлләр кылган өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган дәүләт пошлинасы | 701 | 1 08 07082 01 0000 110 | 494,0 |
| Федераль дәүләт экология контроле кагылмый торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларындагы стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы | 701 | 1 08 07262 01 0000 110 | 1 307,4 |
| Россия Федерациясе территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре буенча җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиядә килешенгән билгеле вакыйгалар барлыкка килгәндә җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер мәртәбә түләүләр | 701 | 1 12 02012 01 0000 120 | 45 056,1 |
| Файдалы казылмалар запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик, икътисадый һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы үткәргән өчен түләү | 701 | 1 12 02052 01 0000 120 | 625,0 |
| Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына конкурста (аукционда) катнашкан өчен җыемнар | 701 | 1 12 02102 02 0000 120 | 695,5 |
| Россия Федерациясе субъектлары мөлкәтеннән файдалануга бәйле тотылган чыгымнарны түләтү тәртибендә алына торган керемнәр | 701 | 1 13 02062 02 0000 130 | 107,7 |

| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Узган еллардагы дебитор бурычларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 701 | 1 13 02992 02 0001 130 | 41 547,5 |
| Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары оештыра һәм үткәрә торган дәүләт экологик экспертизасы узарга тиешле документация заказчылары кертә торган, дәүләт экологик экспертизасы үткәрү чыгымнары сметасы нигезендә исәпләнгән җыемнар | 701 | 1 15 07020 01 0000 140 | 124,1 |
| Федераль милектәге су объектларында билгеләнгән су законнарын бозган өчен Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан салына торган акчалата түләтүләр (штрафлар) | 701 | 1 16 25086 02 0000 140 | 1 226,6 |
| Россия Федерациясе субъектлары ихтыяҗлары өчен, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 701 | 1 16 33020 02 0000 140 | 4,7 |
| Әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турындагы дәгъвалар буенча Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелергә тиешле суммалар | 701 | 1 16 35010 02 0000 140 | 4 811,4 |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган бүтән кертемнәр | 701 | 1 16 90020 02 0001 140 | 19,3 |
| Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контракты шартларын бозган өчен акчалата түләтүләр (неустойка) | 701 | 1 16 90020 02 0003 140 | 7 713,1 |
| Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм бүтән бюджетара трансфертларны муниципаль районнар бюджетларыннан кире кайтарудан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 701 | 2 18 02040 02 0000 151 | 55 063,8 |



| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | 702 | | 21 728,5 |
| Лицензияләүгә, аттестация уздыруга, әгәр мондый аттестация Россия Федерациясе законнарында каралган булса, бәйле рәвештә гамәлләр кылган өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган дәүләт пошлинасы | 702 | 1 08 07082 01 0000 110 | 587,4 |
| Россия Федерациясе субъектлары мөлкәтеннән файдалануга бәйле тотылган чыгымнарны түләтү тәртибендә алына торган керемнәр | 702 | 1 13 02062 02 0000 130 | 2 640,2 |
| Узган еллардагы дебитор бурычларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 702 | 1 13 02992 02 0001 130 | 15 179,8 |
| Россия Федерациясе субъектлары ихтыяҗлары өчен, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 702 | 1 16 33020 02 0000 140 | 121,9 |
| Бюджет учреждениеләре тарафыннан узган еллардан калган субсидияләрне кайтарудан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 702 | 2 18 02010 02 0000 180 | 3 195,6 |
| Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм бүтән бюджетара трансфертларны муниципаль районнар бюджетларыннан кире кайтарудан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 702 | 2 18 02040 02 0000 151 | 3,6 |
| Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | 703 | | 41 526,40 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләрдән) башка керемнәр | 703 | 1 13 01992 02 0000 130 | 39 693,7 |
| Россия Федерациясе субъектлары мөлкәтеннән файдалануга бәйле тотылган чыгымнарны түләтү тәртибендә алына торган керемнәр | 703 | 1 13 02062 02 0000 130 | 769,9 |

| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Узган еллардагы дебитор бурычларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 703 | 1 13 02992 02 0001 130 | 0,3 |
| Россия Федерациясе субъектлары ихтыяҗлары өчен, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 703 | 1 16 33020 02 0000 140 | 0,7 |
| Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контракты шартларын бозган өчен акчалата түләтүләр (неустойка) | 703 | 1 16 90020 02 0003 140 | 74,2 |
| Татарстан Республикасы бюджетының салым булмаган башка керемнәре | 703 | 1 17 05020 02 0001 180 | 987,6 |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | 704 | | 48 471,6 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләрдән) башка керемнәр | 704 | 1 13 01992 02 0000 130 | 3 450,0 |
| Узган еллардагы дебитор бурычларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 704 | 1 13 02992 02 0001 130 | 12 378,5 |
| Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 704 | 1 13 02992 02 0002 130 | 6 525,8 |
| Россия Федерациясе субъектлары ихтыяҗлары өчен, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 704 | 1 16 33020 02 0000 140 | 49,7 |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган бүтән кертемнәр | 704 | 1 16 90020 02 0001 140 | 315,2 |



| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контракты шартларын бозган өчен акчалата түләтүләр (неустойка) | 704 | 1 16 90020 02 0003 140 | 1 061,5 |
| Татарстан Республикасы бюджетының салым булмаган бүтән керемнәре | 704 | 1 17 05020 02 0001 180 | 0,7 |
| Автоном учреждениеләрнең узган еллардан калган субсидияләрне кире кайтаруыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 704 | 2 18 02020 02 0000 180 | 24 540,2 |
| Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм бүтән бюджетара трансфертларны муниципаль районнар бюджетларыннан кире кайтарудан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 704 | 2 18 02040 02 0000 151 | 150,0 |
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | 705 | | 7 563,20 |
| Узган еллардагы дебитор бурычларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 705 | 1 13 02992 02 0001 130 | 4 947,1 |
| Россия Федерациясе субъектлары ихтыяҗлары өчен, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 705 | 1 16 33020 02 0000 140 | 0,6 |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган бүтән кертемнәр | 705 | 1 16 90020 02 0001 140 | 451,5 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган кертемнәр | 705 | 1 17 01020 02 0000 180 | -10,3 |
| Бюджет учреждениеләренең узган еллардан калган субсидияләрне кире кайтаруыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 705 | 2 18 02010 02 0000 180 | 1 214,1 |

| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Автоном учреждениеләрнең узган еллардан калган субсидияләрне кире кайтаруыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 705 | 2 18 02020 02 0000 180 | 346,4 |
| Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм бүтән бюджетара трансфертларны шәһәр округлары бюджетларыннан кире кайтарудан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 705 | 2 18 02030 02 0000 151 | 473,1 |
| Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм бүтән бюджетара трансфертларны муниципаль районнар бюджетларыннан кире кайтарудан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 705 | 2 18 02040 02 0000 151 | 140,7 |
| Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы | 707 | | 4 227,90 |
| Узган еллардагы дебитор бурычларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 707 | 1 13 02992 02 0001 130 | 77,0 |
| Россия Федерациясе субъектлары ихтыяҗлары өчен, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 707 | 1 16 33020 02 0000 140 | 1,2 |
| Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контракты шартларын бозган өчен акчалата түләтүләр (неустойка) | 707 | 1 16 90020 02 0003 140 | 807,2 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган ачыкланмаган кертемнәр | 707 | 1 17 01020 02 0000 180 | 22,8 |
| Татарстан Республикасы бюджетының салым булмаган башка керемнәре | 707 | 1 17 05020 02 0001 180 | 1 914,2 |
| Бюджет учреждениеләренең узган еллардан калган субсидияләрне кире кайтаруыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 707 | 2 18 02010 02 0000 180 | 122,6 |



| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Автоном учреждениеләрнең узган еллардан калган субсидияләрне кире кайтаруыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 707 | 2 18 02020 02 0000 180 | 1 282,9 |
| Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | 708 | | 100 895,9 |
| Лицензияләүгә, аттестация уздыруга, әгәр мондый аттестация Россия Федерациясе законнарында каралган булса, бәйле рәвештә гамәлләр кылган өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган дәүләт пошлинасы | 708 | 1 08 07082 01 0000 110 | 5 260,9 |
| Юридик әһәмиятле башка гамәлләр кылган өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына күчерелергә тиешле башка дәүләт пошлиналары | 708 | 1 08 07300 01 0000 110 | 3,0 |
| Мәгариф өлкәсендә тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләре чикләрендә Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының мәгариф учреждениеләренең дәүләт аккредитациясенә бәйле гамәлләре өчен дәүләт пошлинасы | 708 | 1 08 07380 01 0000 110 | 8 758,3 |
| Мәгариф өлкәсендә тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләре чикләрендә Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының белем турында, гыйльми дәрәҗәләр һәм гыйльми исемнәр турында дәүләт үрнәгендәге документларда апостиль кую гамәлләре өчен дәүләт пошлинасы | 708 | 1 08 07390 01 0000 110 | 831,5 |
| Узган еллардагы дебитор бурычларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 708 | 1 13 02992 02 0001 130 | 6 898,9 |
| Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 708 | 1 13 02992 02 0002 130 | 5 496,2 |
| Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары карамагындагы учреждениеләрнең оператив идарәсендә булган мөлкәтне (моңа Россия Федерациясе субъектларының бюджет һәм автоном учреждениеләре мөлкәте керми) реализацияләүдән керемнәр, әлеге мөлкәт буенча матди запасларны реализацияләү өлешендә | 708 | 1 14 02022 02 0000 440 | 8,6 |

| Күрсәткеч исеме | Бюджет классификациясе коды | | Касса үтәлеше |
|---|---|---|---|
| | кертемнәрнең администраторы | Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре | |
| Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контракты шартларын бозган өчен акчалата түләтүләр (неустойка) | 708 | 1 16 90020 02 0003 140 | 2 424,1 |
| Татарстан Республикасы бюджетының салым булмаган башка керемнәре | 708 | 1 17 05020 02 0001 180 | 67,6 |
| Бюджет учреждениеләренең узган еллардан калган субсидияләрне кире кайтаруыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 708 | 2 18 02010 02 0000 180 | 19 665,6 |
| Автоном учреждениеләрнең узган еллардан калган субсидияләрне кире кайтаруыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 708 | 2 18 02020 02 0000 180 | 33 194,8 |
| Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм бүтән бюджетара трансфертларны шәһәр округлары бюджетларыннан кире кайтарудан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 708 | 2 18 02030 02 0000 151 | 11 548,8 |
| Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм бүтән бюджетара трансфертларны муниципаль район бюджетларыннан кире кайтарудан Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары керемнәре | 708 | 2 18 02040 02 0000 151 | 6 737,6 |
| Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы | 709 | | 177 634,5 |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары акчаларын алучылар тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән (эшләрдән) башка керемнәр | 709 | 1 13 01992 02 0000 130 | 6 622,6 |
| Россия Федерациясе субъектлары мөлкәтеннән файдалануга бәйле тотылган чыгымнарны түләтү тәртибендә алына торган керемнәр | 709 | 1 13 02062 02 0000 130 | 6 629,2 |
| Узган еллардагы дебитор бурычларын кире кайтарудан Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 709 | 1 13 02992 02 0001 130 | 163 837,6 |
1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Т.Г. Һадиев һәм Р.Р. Гайзатуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 219-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2016 елның 10 июненә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2016 елның 30 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1263-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 446. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында» 230-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары С.М. Захарова, Р.Г. Ногманов тарафыннан кертелгән «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында» 230-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2016 елның 14 июненә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты әлеге закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2016 елның 30 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1264-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 447. «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 223-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 223-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1265-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 448. «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (223-5 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (223-5 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1266-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 449. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү нигезләре һәм тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 105 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү нигезләре һәм тәртибе хакындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1267-V ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
2016 елның 31 маендагы 1267-V ДС номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү нигезләре һәм тәртибе хакында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының (алга таба – депутат) үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү нигезләрен һәм тәртибен билгели.

2. Депутат, түбәндәге нигезләрнең берсе йә берничәсе булганда, үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына

китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш:

1) депутатның акчалата, бүтән төрле мөлкәт рәвешендә, шул исәптән мөлкәт хокуклары рәвешендә, керемнәр алу, мөлкәти характердагы хезмәтләр күрсәтелү, башкарган эшләрнең нәтиҗәләрен яисә нинди дә булса файда (өстенлекләр) алу ихтималы булу;

2) депутат белән якын кардәшлектә яисә үги туганлыкта (ата-анасы, ире (хатыны), балалары, абыйлары, апалары, шулай ук ир белән хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары, балалары һәм балаларының ире (хатыны) булган затларның акчалата, бүтән төрле мөлкәт рәвешендә, шул исәптән мөлкәт хокуклары рәвешендә, керемнәр алу, мөлкәти характердагы хезмәтләр күрсәтелү, башкарган эшләрнең нәтиҗәләрен яисә нинди дә булса файда (өстенлекләр) алу ихтималы булу;

3) депутат һәм (яисә) аның белән якын кардәшлектә яисә үги туганлыкта булган затлар белән мөлкәти, корпоратив яисә башка якын мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән гражданнарның йә оешмаларның акчалата, бүтән төрле мөлкәт рәвешендә, шул исәптән мөлкәт хокуклары рәвешендә керемнәр алу, мөлкәти характердагы хезмәтләр күрсәтелү, башкарган эшләрнең нәтиҗәләрен яисә нинди дә булса файда (өстенлекләр) алу ихтималы булу.

3. Депутат, әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр булса, үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә (алга таба – Комиссия) хәбәр итә. Комиссия рәисе депутаттан үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр алуы хакында кичекмәстән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә мәгълүмат бирергә тиеш.

4. Хәбәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) рәвешендә язмача әлеге Нигезләмәнең кушымтасына нигезләнеп рәсмиләштерелә.

5. Хәбәрнамә депутатның үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин



булган шәхси кызыксынуы барлыкка килгән көннән башлап йә бу хакта депутатка билгеле булган көннән башлап өч эш көне эчендә депутат тарафыннан бирелергә тиеш.

6. Шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән срокта җитди сәбәпләр аркасында (авыру, отпуск, командировкада булу) хәбәр итеп булмаганда, депутат шәхси кызыксынуы булу турында әлеге пунктта каралган шартлар беткән көннән соңгы өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

7. Хәбәрнамә биргән көндә депутатка хәбәрнамәнең аны теркәү турында тамга куелган күчермәсе кире кайтарыла.

8. Комиссия тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) депутат биргән мәгълүматны һәм тикшерү материалларына беркетелә торган өстәмә материалларны өйрәнергә;

2) аларга бирелгән мәгълүмат һәм өстәмә материаллар буенча депутаттан аңлатмалар алырга;

3) Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына, башка федераль дәүләт органнарына, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга депутат мәгълүматында күрсәтелгән мәнфәгатьләр конфликты мәсьәләсе буенча соратуларын билгеләнгән тәртиптә җибәрергә;

4) тикшерү барышында алынган белешмәләргә коррупциягә каршы тору турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә анализ ясарга.

9. Депутат, үзе биргән хәбәрнамә карап тикшерелгәндә, Комиссия утырышында катнашырга хокуклы. Күрсәтелгән хәбәрнамәнең Комиссия утырышында каралу датасы турында депутатка Комиссия рәисе хәбәр итә.

10. Комиссия, хәбәрнамәне караганнан соң, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) хәбәрнамә юллаган депутатның депутат вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтының булмавын танырга;

2) хәбәрнамә юллаган депутатның депутат вәкаләтләрен башкарганда аның шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр конфликтына китерүен яисә китерә алуын танырга.

11. Комиссия тарафыннан хәбәрнамәнең каралу һәм аның карар кабул итү срогы Комиссиягә хәбәрнамә кергән көннән 30 календарь көннән күбрәк була алмый. Әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән өстәмә аңлатмалар һәм мәгълүмат таләп ителгән очракта, Комиссия рәисе хәбәрнамәне карау срогын 60 көнгә кадәр озайта ала.

12. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 10 пунктындагы 2 пунктчасында каралган карарны кабул иткән очракта, депутатка Рос-

сия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу буенча чаралар күрергә тәкъдим ителә.

13. Комиссия карары хәбәрнамә юллаган депутатка, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә аны кабул иткән көннән башлап өч эш көне эчендә җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатының
үз вәкаләтләрен башкарганда
мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган
яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы
барлыкка килү турында хәбәр итү
нигезләре һәм тәртибе хакындагы нигезләмәгә
кушымта

______________________
(танышу турында тамга)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясенә

________________________________

________________________________
(депутатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының
үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына
китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы
барлыкка килү хакында
ХӘБӘРНАМӘ

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^5$ статьясы нигезендә мин Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә



китерергә мөмкин шәхси кызыксынуым барлыкка килү турында хәбәр итәм (кирәклесенә сызарга).

Шәхси кызыксыну барлыкка килүгә нигез булып торучы шартлар:

________________________________________________
________________________________________________
________________________________________________

Шәхси кызыксыну түбәндәге вәкаләтләрне үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясарга мөмкин:

________________________________________________
________________________________________________
________________________________________________

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу өчен тәкъдим ителә һәм (яисә) күрелә торган чаралар:

________________________________________________
________________________________________________
________________________________________________

«__»______, 20_ ел, __________________ ____________________
(хәбәрнамә җибәргән (имзаны аңлатып язу)
депутат имзасы)

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 450. «Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе хакындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 29 ноябрендәге 2545-IV ДС номерлы карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе хакындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2012 елның 29 ноябрендәге 2545-IV ДС номерлы карары белән расланган Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе хакындагы нигезләмәгә, аңа түбәндәге эчтәлекле $1.1^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$1.1^1$. Комиссия Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының үз вәкаләтләрен үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүләрен карый, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының үз вәкаләтләрен үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итүе нигезләре һәм тәртибе хакындагы нигезләмәгә таянып, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә хәл итү чараларын күрү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына тәкъдимнәр әзерләүне башкара.».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1268-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 451. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать кабул итү бүлмәләре һәм җәмәгать ярдәмчеләре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 елның 20 ноябрендәге 2376 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать кабул итү бүлмәләре һәм җәмәгать ярдәмчеләре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 елның 20 ноябрендәге 2376 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары кушымтасына, 1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Ярдәмчеләр Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын, шулай ук муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын били алмыйлар.».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1269-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 452. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ант итү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2000 елның 29 июнендәге 207 номерлы карары кушымтасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ант итү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2000 елның 29 июнендәге 207 номерлы карары кушымтасына, «Татарстан Республикасына

тугрылыклы булырга, кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен якларга, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үземә йөкләнгән югары бурычларын намус белән үтәргә тантаналы рәвештә сүз бирәм» сүзләрен «Татарстан Республикасына тугрылыклы булырга, кеше һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен якларга, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үземә йөкләнгән бурычларын намус белән үтәргә ант итәм» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1270-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 453. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 333[33] статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 333[33] статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертергә.
2. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 333[33] статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын бәяләмә бирү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенә җибәрергә.
3. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 333[33] статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Хөкүмәте бәяләмәсен алганнан соң Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.



4. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Татарстан Республикасыннан сайланган депутатларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.
5. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында күрсәтелгән федераль закон проектын караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты И.И. Гыйльметдиновны билгеләргә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1271-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 454. «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Хөкүмәтенә бәяләмә алу өчен җибәрергә.

3. «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын, аңа Россия Федерациясе Хөкүмәтеннән бәяләмә алганнан соң, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны үтенеп, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына мөрәҗәгать итәргә.

5. Күрсәтелгән закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкил итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты И.И. Гыйльметдиновны билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанс комитетына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1272-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 455. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты составындагы үзгәреш турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Фомичев Андрей Геннадьевичны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты әгъзасы итеп сайларга.

2. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетын сайлау турында» 2014 елның 1 октябрендәге 15-V ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

икенче абзацта «14» санын «15» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «Салихов Илгиз Мисбах улы» сүзләреннән соң «Фомичев Андрей Геннадьевич» сүзләрен өстәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1273-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 456. «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Ярославль өлкә Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1274-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 457. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39[8] статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чиләбе өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39[8] статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чиләбе өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Чиләбе өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1275-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 458. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 35 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1035350-6 номерлы федераль закон проекты турында (беренче тапкыр эш эзләүче (элек эшләмәгән) һәм шул ук вакытта квалификациясе булмаган гражданнар, озак вакытлы (бер елдан артыграк) тәнәфестән соң хезмәт эшчәнлеген яңартырга омтылучы гражданнар түләүле җәмәгать эшләрендә катнашудан баш тарткан очракта пособие түләүне туктатып тору өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 35 статьясына



үзгәрешләр кертү хакында» 1035350-6 номерлы федераль закон проектын (беренче тапкыр эш эзләүче (элек эшләмәгән) һәм шул ук вакытта квалификациясе булмаган гражданнар, озак вакытлы (бер елдан артыграк) тәнәфестән соң хезмәт эшчәнлеген яңартырга омтылучы гражданнар түләүле җәмәгать эшләрендә катнашудан баш тарткан очракта пособие түләүне туктатып тору өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1276-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 459. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Томск өлкәсе Закон чыгару Думасының закон чыгару инициативасы турында (инвалидлар һәм инвалид балалы гаиләләр өчен торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә кую сроклары хакындагы норманы юкка чыгару мәсьәләсе буенча)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Томск өлкәсе Закон чыгару Думасының закон чыгару инициативасын (инвалидлар һәм инвалид балалы гаиләләр өчен торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә кую сроклары хакындагы норманы юкка чыгару мәсьәләсе буенча) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1277-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 460. «Хәрби хезмәт узган, эчке эшләр органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтендә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен тикшереп тору органнарында, җинаять-үтәтү учреждениеләрендә һәм органнарында хезмәт узган затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Хәрби хезмәт узган, эчке эшләр органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтендә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен тикшереп тору органнарында, җинаять-үтәтү учреждениеләрендә һәм органнарында хезмәт узган затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1278-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 461. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 32 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1032385-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль хезмәт һәм дәүләт граждан хезмәте узганда чикләүләрнең һәм бурычларның бердәйлеген тәэмин итү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 32 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1032385-6 номерлы федераль закон проектын (муниципаль хезмәт һәм дәүләт граждан хезмәте узганда чикләүләрнең һәм бурычларның бердәйлеген тәэмин итү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1279-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 462. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1035996-6 номерлы федераль закон проекты турында (депутат эшчәнлегенә бәйле өстәмә чикләүләр өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның

12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1035996-6 номерлы федераль закон проектын (депутат эшчәнлегенә бәйле өстәмә чикләүләр өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1280-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 463. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 24 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1045026-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатын чакыртып алу мәсьәләсе буенча)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 24 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1045026-6 номерлы федераль закон проектын (муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатын чакыртып алу мәсьәләсе буенча) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1281-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 464. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 11 статьясындагы 12 өлешенә үзгәреш кертү хакында» 1034586-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт хезмәте системасының бердәйлеген тәэмин итү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 11 статьясындагы 12 өлешенә үзгәреш кертү хакында» 1034586-6 номерлы федераль закон проектын (дәүләт хезмәте системасының бердәйлеген тәэмин итү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1282-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 465. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 164 һәм 165 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 164 һәм 165 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1283-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 466. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1071218-6 номерлы федераль закон проекты турында (юлларны төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү таләпләрен үтәмәгән өчен җаваплылык билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 1071218-6 номерлы федераль закон проектын (юлларны төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү таләпләрен үтәмәгән өчен җаваплылык билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1284-V ДС



## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 467. «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» Федераль законның 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1050451-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының край, өлкә составына керүче автономияле округ территориясендә гамәлгә ашырыла торган мобилизацион әзерлек һәм мобилизация өлкәсендәге вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» Федераль законның 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1050451-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнарының край, өлкә составына керүче автономияле округ территориясендә гамәлгә ашырыла торган мобилизацион әзерлек һәм мобилизация өлкәсендәге вәкаләтләрен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1285-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 468. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1037638-6 номерлы федераль закон проекты турында (Кодексның 19.4, 19.4[1], 19.5 статьяларында каралган хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тарту вакытын арттыру хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 4.5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1037638-6 номерлы федераль закон проектын (Кодексның 19.4, 19.4[1], 19.5 статьяларында каралган хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тарту вакытын арттыру хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1286-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 469. «Юл хәрәкәте иминлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1046974-6 номерлы федераль закон проекты турында («авария куркынычы булган юл участогы» төшенчәсен кертү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Юл хәрәкәте иминлеге турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1046974-6 номерлы федераль закон проектын («авария куркынычы булган юл участогы» төшенчәсен кертү хакында) хупларга.



2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1287-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 470. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1027801-6 номерлы федераль закон проекты турында (спортта куллану тыелган субстанцияләрне һәм (яисә) ысулларны спортчыларга карата куллану өлешендә административ хокук бозу составын төгәлләштерү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә:**

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1027801-6 номерлы федераль закон проектын (спортта куллану тыелган субстанцияләрне һәм (яисә) ысулларны спортчыларга карата куллану өлешендә административ хокук бозу составын төгәлләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 31 мае
№ 1288-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 471. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче утырышын 2016 елның 31 маенда 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 24 мае
№ 1230-V ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 472. Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының унсигезенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.

2. Татарстан Республикасы Казан шәһәренең Яңа Савин суд районы буенча 9 нчы суд участогы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.

3. «2015 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 233-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

4. «2015 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 234-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).



5. «Татарстан Республикасында театрлар һәм театр эше турында» 185-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

6. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 192-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

7. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законының 13 һәм $13^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 220-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 226-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасы Казан шәһәре суд районнары буенча җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Казан шәһәрендә районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 224-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пункты дүртенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 232-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 237-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 238-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 219-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 230-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үз-

гәреш кертү хакында» 223-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатының үз вәкаләтләрен башкарганда мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү нигезләре һәм тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында.

17. «Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комиссиясе хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2012 елның 29 ноябрендәге 2545-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәреш кертү хакында.

18. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать кабул итү бүлмәләре һәм җәмәгать ярдәмчеләре турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2003 елның 20 ноябрендәге 2376 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында.

19. «Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ант итү тәртибен раслау турында» 2000 елның 29 июнендәге 207 номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында.

20. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге $333^{33}$ статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

21. «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» Федераль законның 19 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.

22. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты составындагы үзгәреш турында.

23. «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ярославль өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында.



24. «Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{8}$ статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чиләбе өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

25. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 35 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1035350-6 номерлы федераль закон проекты турында (беренче тапкыр эш эзләүче (элек эшләмәгән) һәм шул ук вакытта квалификациясе булмаган гражданнар, озак вакытлы (бер елдан артыграк) тәнәфестән соң хезмәт эшчәнлеген яңартырга омтылучы гражданнар түләүле җәмәгать эшләрендә катнашудан баш тарткан очракта пособие түләүне туктатып тору өлешендә).

26. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Томск өлкәсе Закон чыгару Думасының закон чыгару инициативасы турында (инвалидлар һәм инвалид балалы гаиләләр өчен торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә кую сроклары хакындагы норманы юкка чыгару мәсьәләсе буенча) .

27. «Хәрби хезмәт узган, эчке эшләр органнарында, Дәүләт янгынга каршы хезмәтендә, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен тикшереп тору органнарында, җинаять-үтәтү учреждениеләрендә һәм органнарында хезмәт узган затларны һәм аларның гаиләләрен пенсия белән тәэмин итү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

28. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 32 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 1032385-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль хезмәт һәм дәүләт граждан хезмәте узганда чикләүләрнең һәм бурычларның бердәйлеген тәэмин итү өлешендә).

29. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» 1035996-6 номерлы федераль закон проекты турында (депутат эшчәнлегенә бәйле өстәмә чикләүләр өлешендә).

30. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 24 статьясы-

на үзгәреш кертү хакында» 1045026-6 номерлы федераль закон проекты турында (муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатын чакыртып алу мәсьәләсе буенча).

31. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 11 статьясындагы 12 өлешенә үзгәреш кертү хакында» 1034586-6 номерлы федераль закон проекты турында (дәүләт хезмәте системасының бердәйлеген тәэмин итү өлешендә).

32. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 164 һәм 165 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Ленинград өлкәсе Закон чыгару собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

33. Хөкүмәт сәгате: «Балигъ булмаганнарның эшләре буенча комиссияләрнең балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалаудагы һәм аларның хокукларын яклаудагы эшчәнлеге турында».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 24 мае
№ 1231-V ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## 473. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты каршындагы Эксперт советы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты каршында Эксперт советы булдырырга.
2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты каршындагы Эксперт советы составын расларга (кушымта итеп бирелә).

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе**
**Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2016 елның 24 мае
№ 1233-V ДС



Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2016 елның 24 маендагы
1233-V ДС номерлы карарына
кушымта

### Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты каршындагы Эксперт советы составы

| | |
|---|---|
| Липужина Валентина Николаевна | I – IV чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Эксперт советы рәисе (килешү буенча) |
| Ощепков Андрей Александрович | «АК БАРС» БАНК гавами акционер җәмгыятенең Региональ бизнес һәм хокукый тәэмин итү дирекциясе Хокук идарәсе башлыгы, Эксперт советы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гыйләҗев Искәндәр Аяз улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты, тарих фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәк өйрәнү институты директоры (килешү буенча) |
| Григорьева Елена Борисовна | Татарстан Республикасында Үзәк сайлау комиссиясе аппаратының хокук бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| Корманова Луиза Мансуровна | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлек-ләр советының башкарма секретаре урынбасары – юридик идарә башлыгы (килешү буенча) |
| Матвеева Светлана Петровна | Татарстан Республикасы Кайбыч районының Хуҗа Хәсән авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мусаев Ренар Габдрахман улы | Доцент, философия фәннәре докторы, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Югары идарә мәктәбе директоры (килешү буенча) |
| Солтанов Евгений Батыр улы | Казан (Идел буе) федераль университеты юридик факультетының конституциячел хокук һәм кеше хокуклары кафедрасы мөдире (килешү буенча) |
| Яковлев Виктор Иосифович | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты аппараты җитәкчесе урынбасары – Хокук идарәсе башлыгы |
| Галиева Гөлфия Рәүф кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Оештыру идарәсенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенең баш киңәшчесе, Эксперт советы җаваплы секретаре |

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

### 474. 18 нче Мәләкәс сайлау округы буенча бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын өстәмә сайлауларны әзерләүгә һәм уздыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчаларны тоту турында һәм кандидатларның сайлау фондларына акчалар керү һәм әлеге акчаларны тоту турында белешмәләр хакында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе хисабы турында

